КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 7 апрель г.Казань № 365

2026 – 2028 елларда «Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2026 – 2028 елларда «Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 29 сентябрь, 778 нче
карары белән расланды

# 2026 – 2028 елларда «Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2026 – 2028 елларда «Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булып тормаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – сайлап алуда катнашучылар, субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирүнең максаты – физика һәм химия буенча белем бирүне үстерүгә, физиканы һәм химияне популярлаштыруга, педагогларга ярдәм итүгә, цифрлы һәм мультимедиалы белем бирү материаллары булдыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын үз эченә алган «Физик-химик алгарыш» проектын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

1.3. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына һәм план чорына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчасы белән баш эш итүче функцияләрен гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык).

1.4. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

субсидия алучы персоналының, шул исәптән административ персоналының «Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле хезмәте өчен түләү, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләү буенча башка түләүләр һәм түләүләргә исәпләүләр;

«Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә,

заявка бирү датасына төзелгән һәм (яки) төзергә планлаштырыла торган кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында шартнамәләр буенча, шул исәптән аның башкаручысы физик зат, индивидуаль эшмәкәр яки юридик зат булган гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр, файдалану хокукына ия махсуслаштырылган программа продуктлары сатып алуны, җиһазлар арендалауны, тәҗрибәләр һәм дәресләр үткәрү өчен чыгым материаллары сатып алуны, китаплар һәм уку әсбаплары сатып алуны кертеп, товарлар сатып алу турында шартнамәләр, уникаль белем бирү ресурсларын булдыру турында шартнамәләр һәм башка шартнамәләр буенча түләү;

«Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга бәйле командировка чыгымнары.

1.5. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + \ldots + З_n,$$

монда $З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – әлеге Тәртипнең 1.4 пунктындагы икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтларын кертеп) булган хезмәт күрсәтү турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар суммасы.

1.6. 2026 елда субсидия бирү нәтиҗәләре:

«Физика буенча интерактив мультимедиа мәсьәләләре» цифрлы уку әсбабы булу – рус һәм татар телләрендә төрлечә белешмәләр бирелгән кимендә 50 интерактив мәсьәлә, 100 видеомәсьәлә һәм кимендә 500 мәсьәлә;

органик һәм органик булмаган химия буенча ике уку әсбабы булу – рус һәм татар телләрендә экспериментлар турында кимендә 25 видеоролик һәм 30 интерактив лаборатор эш;

Татарстанның төгәл фәннәр тарихының виртуаль музее булу – кимендә 105 видеоролик, 35 электрон плакат, 30 мәкалә һәм кимендә 10 аудиоязма;

«Физика-химик алгарыш» проекты сайты булу;

химия буенча үткәрелгән «ХимФест» фестивальләре саны – кимендә 1 600 белем алучы җәлеп итеп, кимендә 4 фестиваль;

интерактив музейга оешкан рәвештә килүчеләр саны – кимендә 9 000 белем алучы һәм кимендә 700 педагогик хезмәткәр;

үткәрелгән белем бирү һәм/яки башка чаралар саны:

робототехника түгәрәкләре – кимендә 200 белем алучы;

предприятиеләргә һәм әйдәүче тикшеренү институтларына фәнни-танып белү экскурсияләре – кимендә 2 000 белем алучы җәлеп итеп, кимендә 50 экскурсия;

радиохимия һәм атом-төш медицинасы буенча лекторияләр, мастер-класслар – кимендә 1 500 белем алучы;

химиядән белем бирә торган өстәл уеннары буенча үткәрелгән сеанслар саны – кимендә 2 500 белем алучы;

мәктәп китапханәләрен комплектлау өчен физика һәм химия буенча кайтартылган китаплар саны – кимендә 50 комплект һәм кимендә 5 000 нөсхә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары өчен химия буенча фәнни уеннарның сатып алынган җыелмалары саны – кимендә 1 500 уеннар җыелмасы.

2027 елда субсидия бирү нәтиҗәләре:

«Физика буенча интерактив мультимедиа мәсьәләләре» дигән цифрлы уку әсбабын кулланып үткәрелгән белем бирү чаралары саны – 1 000 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр җәлеп итеп, кимендә 34 чара;

органик һәм органик булмаган химия буенча уку әсбапларын кулланып үткәрелгән белем бирү чаралары саны – 600 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр җәлеп итеп, кимендә 25 чара;

Татарстанның төгәл фәннәр тарихы буенча виртуаль музеена актив килүчеләр саны – кимендә 10 000 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр;

«Физик-химик алгарыш» проекты сайтын актив кулланучылар һәм уникаль караулар саны – кимендә 5 500 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр;

5 – 6 нчы сыйныфларның белем алучылары өчен «Физика. Башлангыч» анимацияле сериалы булуы – кимендә 12 серия;

химия буенча үткәрелгән «ХимФест» фестивальләре саны – кимендә 1 700 белем алучы җәлеп итеп, кимендә 4 фестиваль;

интерактив музейга оешкан рәвештә килүчеләр саны – кимендә 9 000 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр;

үткәрелгән белем бирү һәм/яки башка чаралар саны:

робототехника буенча түгәрәкләр – кимендә 250 белем алучы;

предприятиеләргә һәм әйдәүче тикшеренү институтларына фәнни-танып белү экскурсияләре – кимендә 2 500 белем алучы җәлеп итеп, кимендә 50 экскурсия;

механика һәм инженерия, радиохимия һәм атом-төш медицинасы буенча лекторияләр, мастер-класслар – кимендә 2 500 белем алучы;

химиядән белем бирә торган өстәл уеннары буенча үткәрелгән сеанслар саны – кимендә 3 500 белем алучы;

мәктәп китапханәләрен комплектлау өчен физика һәм химия буенча кайтартылган китаплар саны – кимендә 50 комплект һәм кимендә 5 000 нөсхә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары өчен химия буенча фәнни уеннарның сатып алынган җыелмалары саны – кимендә 1 500 уеннар җыелмасы.

2028 елда субсидия бирү нәтиҗәләре:

«Физика буенча интерактив мультимедиа мәсьәләләре» дигән цифрлы уку әсбабын кулланып үткәрелгән белем бирү чаралары саны – 1 500 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр җәлеп итеп, кимендә 34 чара;

органик һәм органик булмаган химия буенча уку әсбапларын кулланып үткәрелгән белем бирү чаралары саны – 1 200 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр җәлеп итеп, кимендә 25 чара;

Татарстанның төгәл фәннәр тарихы буенча виртуаль музеена актив килүчеләр саны – кимендә 15 000 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр;

«Физик-химик алгарыш» проекты сайтын актив кулланучылар һәм уникаль

караулар саны – кимендә 7 500 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр;

5 – 6 нчы сыйныфларның белем алучылары өчен «Физика. Башлангыч» анимацияле сериалын кулланучылар саны – кимендә 1 500 белем алучы;

химия буенча үткәрелгән «ХимФест» фестивальләре саны – кимендә 1 800 белем алучы җәлеп итеп, кимендә 4 фестиваль;

интерактив музейга оешкан рәвештә килүчеләр саны – кимендә 9 000 белем алучы һәм педагогик хезмәткәр;

үткәрелгән белем бирү һәм/яки башка чаралар саны:

робототехника буенча түгәрәкләр – кимендә 300 белем алучы;

предприятиеләргә һәм әйдәүче тикшеренү институтларына фәнни-танып белү экскурсияләре – кимендә 2 800 белем алучы җәлеп итеп, кимендә 50 экскурсия;

механика һәм инженерия, радиохимия һәм атом-төш медицинасы буенча лекторияләр, мастер-класслар – кимендә 2 800 белем алучы;

химиядән белем бирә торган өстәл уеннары буенча үткәрелгән сеанслар саны – кимендә 3 500 белем алучы;

мәктәп китапханәләрен комплектлау өчен физика һәм химия буенча кайтартылган китаплар саны – кимендә 50 комплект һәм кимендә 5 000 нөсхә;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары өчен химия буенча фәнни уеннарның сатып алынган җыелмалары саны – кимендә 1 500 уеннар җыелмасы.

Субсидия бирү нәтиҗәләре 2026 елда – 2026 елның 31 декабренә кадәр, 2027 елда – 2027 елның 31 декабренә кадәр, 2028 елда 2028 елның 31 декабренә кадәр ирешелергә тиеш.

1.7. Субсидия алучыны сайлап алуны (алга таба – сайлап алу) үткәрү ысулы – тәкъдимнәр (заявкалар) (алга таба – заявка) сорау – сайлап алуны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкаларның керү чиратыннан чыгып үткәрү.

1.8. Субсидия турында мәгълүмат субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал бүлегендә) Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

1.9. Субсидия бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

1.10. Субсидия алучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

сайлап алу турында белдерү урнаштыру датасына кимендә өч ел рәттән дәреслекләр, уку әсбаплары, китаплар, әдәби-анимацияле басмалар, мобиль кушымталар, сайтлар, интерактив мультимедиа материаллары, анимацияле фильмнар, интерактив видеоматериаллар, интерактив плакатлар булдыру тәҗрибәсе булырга тиеш;

сайлап алу турында белдерү урнаштыру датасына кимендә өч ел рәттән иҗат ителгән анимацияле фильмнар/сериаллар өчен Россия Федерациясе Мәдәният

министрлыгы тарафыннан субсидия алучыга бирелгән прокат таныклыклары булырга тиеш;

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда файдаланырга рөхсәт ителгән уку әсбапларын чыгаруны гамәлгә ашыра торган оешмалар исемлеген раслау турында» 2016 елның 9 июнендәге 699 номерлы боерыгы белән расланган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең дәүләт аккредитациясе булган белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда файдаланырга рөхсәт ителгән уку әсбапларын чыгаруны гамәлгә ашыра торган оешмалар исемлегенә кертелгән булырга тиеш.

## II. Сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр

2.1. Заявканы карау һәм субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү даталарына карата сайлап алуда катнашучы түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормау;

БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына

салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмый яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы булмый (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмый.

2.2. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә сайлап алуда катнашучының туры килү-килмәвен тикшерү сайлап алуны үткәрүне тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт мәгълүмат системалары) мәгълүматлары нигезендә, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын файдаланып, «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында (алга таба – «Электрон бюджет» системасы) автомат рәвештә гамәлгә ашырыла.

«Электрон бюджет» системасында автомат рәвештә тикшерүне гамәлгә ашыру өчен техник мөмкинлек булмаган очракта, сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау сайлап алуда катнашучы тарафыннан «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән әлеге таләпләргә туры килү-килмәү турындагы билгеләрне электрон рәвештә язып кую юлы белән гамәлгә ашырыла.

Министрлык, ведомствоара электрон хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның файдалану мөмкинлеге булган дәүләт мәгълүмат системаларында тиешле мәгълүмат булганда, әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә сайлап алуда катнашучының туры килүен раслый торган документлар тапшыруны (әгәр сайлап алуда катнашучы әлеге документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы белән Министрлыкка тапшырырга әзер булган очрактан тыш) таләп итәргә хокуксыз.

## III. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү булдыру һәм урнаштыру тәртибе

3.1. Сайлап алу Министрлык тарафыннан «Электрон бюджет» системасында гамәлгә ашырыла. Министрлык белән сайлап алуда катнашучыларның үзара хезмәттәшлеге «Электрон бюджет» системасында электрон формадагы документларны файдаланып гамәлгә ашырыла.

3.2. «Электрон бюджет» системасыннан файдалану мөмкинлеге «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм

системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

3.3. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан, «Электрон бюджет» системасында Министрлык белдерүне формалаштырган көннән алып биш эш көннән дә соңга калмыйча, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланып, бердәм порталда субсидия турында мәгълүмат басылып чykканнан соң урнаштырыла.

3.4. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү Министрлык тарафыннан «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсындагы тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда бастырып чыгарыла, түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкалар бирә башлау һәм кабул итү тәмамлану датасы, шул ук вакытта заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән дә иртәрәк була алмый;

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

әлеге Тәртипнең 1.6 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләре;

«Интернет» челтәрендәге дәүләт мәгълүмат системасының домен исеме һәм (яки) битләре күрсәткечләре;

сайлап алуда катнашучы әлеге Тәртип белән билгеләнгән датага туры килергә тиешле әлеге Тәртипнең 2.1 пункты белән билгеләнгән сайлап алуда катнашучыларга һәм күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлегенә карата таләпләр;

сайлап алу критерийлары;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртипнең 5.1 – 5.6 пунктлары нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

әлеге Тәртипнең 5.7 пункты нигезендә заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртипнең 6.1 – 6.4 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

эшләп бетерү өчен заявкаларны кире кайтару тәртибе;

заявкаларны кабул итмәү тәртибе, шулай ук аларны кабул итмәү нигезләре турында мәгълүмат;

сайлап алу кысаларында бүленә торган субсидия күләме, әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибе, сайлап алуның җиңүчеләренә бирелә торган субсидиянең максималь, минималь күләмен үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре буенча субсидияне бүлү кагыйдәләре, шулай ук сайлап алуда җиңүчеләрнең иң чик саны;

сайлап алуда катнашучыларга әлеге Тәртипнең 5.8, 5.9 пунктлары нигезендә

сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатма бирү срогы башлану датасы һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуның җиңүчесе әлеге Тәртипнең 7.1 пункты нигезендә килешү имзаларга тиеш вакыт;

сайлап алуда җиңүчене әлеге Тәртипнең 7.5 пункты нигезендә килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда, шулай ук «Интернет» челтәрендә https://mon.tatarstan.ru/ Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) сайлап алу йомгакларын үткәрү беркетмәсен урнаштыру сроклары, сайлап алу җиңүчесен билгеләгән көннән соң килүче 14 нче календарь көннән соң була алмый.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү, заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан да соңга калмыйча, әлеге пунктында билгеләнгән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүне формалаштыру тәртибе кебек тәртиптә, түбәндәге шартларны үтәп, гамәлгә ашырыла:

заявкалар бирү срогы мондый үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән заявкаларны кабул итү датасына кадәр әлеге срок кимендә өч календарь көн тәшкил итә торган итеп озайтылырга тиеш;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр керткәндә сайлап алу ысулын үзгәртергә рөхсәт ителми;

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән очракта, заявкалар кабул итә башлау датасы башланганнан соң, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә сайлап алуда катнашучыларның әлеге Тәртипнең 5.7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкага үзгәрешләр кертү хокукы каралган нигезләмә кертелә;

заявка биргән сайлап алуда катнашучыларга, «Электрон бюджет» системасыннан файдаланып, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертелгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүгә үзгәрешләр кертү хакында хәбәр ителә.

## IV. Сайлап алуны үткәрүне гамәлдән чыгару тәртибе

4.1. Министрлык тарафыннан бердәм порталда сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштыру сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча рөхсәт ителә.

4.2. Сайлап алу үткәрүне гамәлдән чыгару турында белдерү «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсындагы тиешле экран формаларын тутыру юлы белән электрон рәвештә булдырыла, Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, бердәм порталда урнаштырыла һәм сайлап алуны гамәлдән чыгару сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

Сайлап алуны гамәлдән чыгару очрагы булып әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын кире алу тора.

4.3. Заявкалар биргән сайлап алуда катнашучылар «Электрон бюджет» системасында сайлап алуны үткәрүне юкка чыгару турында мәгълүмат бирәләр.

4.4. Сайлап алу бердәм порталда аны гамәлдән чыгару турында белдерү урнаштырылган көннән алып гамәлдән чыгарылган дип санала.

## V. Сайлап алуда катнашучылар тарафыннан заявкаларны формалаштыру һәм бирү тәртибе

5.1. Сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән сроклар эчендә «Электрон бюджет» системасының веб-интерфейсындагы тиешле экран формаларын тутыру һәм «Электрон бюджет» системасына документларның (сканерлау юлы белән электрон формага үзгәртелгән кәгазь чыганактагы документларның) электрон күчермәләрен бирү юлы белән заявка булдыра һәм тапшыра:

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе яисә тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган сайлап алуда катнашучының гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләрне кертү турында документлар (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсен теркәп);

«Физик-химик алгарыш» проектының презентациясе (.pptx яки .pdf форматларында структураларга бүлеп һәм визуаль яктан матур итеп эшләнгән, чараның төп аспектларын чагылдыра торган электрон презентациядә проектның исеме, оештыручы, максатчан аудитория күрсәтелгән титул слайды булырга, чараның актуальлеге һәм максатлары күрсәтелергә тиеш, эчтәлек өлешенең тасвирламасы, интерактив элементлар, җәлеп итеп торган экспертлар/җиһазлар, көтелә торган нәтиҗәләр һәм аларны бәяләү критерийлары булырга тиеш);

«Физик-химик алгарыш» проектының аннотациясе (1 500 – 2 500 билгедән торган кыска, әмма эчтәлекле текст тасвирламасы, чараның кыска тасвирнамәсе, форматы, озынлыгы, урыны, төп идеясе һәм уникальлеге, максатчан аудиториясен төгәл билгеләү, формалаштырыла торган компетенцияләр һәм белемнәр исемлеге);

«Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыру белән бәйле сайлап алуда катнашучының планлаштырыла торган чыгымнар турында документлар:

авторлык шартнамәләре, әдәби-анимацияле басмаларга махсус хокукларның күчүе турында шартнамәләр;

«Физик-химик алгарыш» проекты чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнар сметасы;

калькуляция (исәп-хисапларны һәм бәяләр нигезләвен теркәп);

сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) сугылган, ирекле формада язылган, сайлап алуда катнашучының дәреслекләр, уку әсбаплары, китаплар, әдәби-анимацияле басмалар, мобиль кушымталар, сайтлар, интерактив мультимедиы материаллары, анимацияле фильмнар, интерактив видеоматериаллар, интерактив плакатлар булдыру проектларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булу турында белешмә кәгазе;

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыру датасына кимендә өч ел рәттән иҗат ителгән анимацияле фильмнар/сериаллар өчен Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы тарафыннан бирелгән прокат таныклыклары.

5.2. Заявкада түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) сайлап алуда катнашучы турында мәгълүмат:

сайлап алуда катнашучының тулы һәм кыскартылган исеме;

сайлап алуда катнашучының төп дәүләт теркәве номеры;

салым түләүченең идентификация номеры;

сайлап алуда катнашучыны дәүләт теркәвенә алу датасы;

сайлап алуда катнашучының адресы;

элемтәгә керү өчен телефон номеры, почта адресы һәм юридик әһәмиятле хәбәрләр җибәрү өчен электрон почта адресы;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесе турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда));

субсидияне күчерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә счетлар турында, шулай ук килешүне имзалауга вәкаләтле зат турында мәгълүмат;

б) «Интернет» челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән заявка турында, шулай ук «Электрон бюджет» системасы веб-интерфейсының тиешле экран формаларын тутыру юлы белән бирелә торган субсидияне сайлап алуга һәм аның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын раслау;

в) сайлап алуда катнашучы тәкъдим итә торган субсидия бирү нәтиҗәләре, соратып алына торган субсидия күләме.

5.3. Заявка сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең яки ул вәкаләт биргән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

5.4. Заявкада булган мәгълүматның һәм документларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

5.5. Заявкага кертелә торган документларның һәм материалларның электрон күчермәләре киң таралган, мәгълүмат карау өчен гомумфайдаланыла торган программа тәэминаты чаралары белән документны тулысынча яисә аның бер өлешен карау мөмкинлеген тәэмин итә торган ачык форматларда булырга тиеш һәм махсус программа яки технологик чаралар кулланмыйча эчтәлеге белән танышып булмый торган чаралар белән шифрланган яки сакланган булмаска тиеш.

Заявкага кертелгән фото- һәм видеоматериалларда югары сыйфатлы ачык һәм контрастлы сурәт булырга тиеш.

5.6. Сайлап алуда катнашучының заявка бирү датасы итеп «Электрон бюджет» системасында заявкага теркәлү номеры бирелгән, сайлап алуда катнашучы тарафыннан аңа имза куелган көн санала.

5.7. Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алуны үткәрү тәмамлану датасына кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда, сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

Заявкага үзгәрешләр кертү яки заявканы кире алу сайлап алуда катнашучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 5.1 пунктында күрсәтелгән сайлап алуда катнашучы заявкасын формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.8. Теләсә кайсы сайлап алуда катнашучы, бердәм порталда сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән алып заявкалар бирү тәмамланган

көнгә кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында тиешле рәсми сорау формалаштыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләрен аңлату турында иң күбе ике рәсми сорау җибәрергә хокуклы.

5.9. Министрлык, әлеге Тәртипнең 5.8 пунктында күрсәтелгән рәсми сорауга җавап итеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән срок эчендә, әмма заявкалар бирү тәмамлану көненә кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасында тиешле аңлатма булдыру юлы белән сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә аңлатма җибәрә. Министрлык тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү нигезләмәләренә бирелгән аңлатма әлеге белдерүдәге мәгълүматның асылын үзгәртмәскә тиеш.

«Электрон бюджет» системасында формалаша торган аңлатмадан файдалану әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә сайлап алуның барлык катнашучыларына бирелә.

## VI. Заявкаларны карап тикшерү, шулай ук сайлап алуда җиңүчене билгеләү тәртибе

6.1. Заявкаларны карап тикшерү Министрлык тарафыннан «Электрон бюджет» системасында заявкаларны карап тикшерү өчен Министрлыкка кереп карау мөмкинлеге бирелгән көннән соң килә торган 10 эш көне эчендә башкарыла.

Министрлыкка «Электрон бюджет» системасына керү мөмкинлеге сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкалар бирү срогы тәмамланган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә.

«Электрон бюджет» системасында Министрлык тарафыннан заявкалар бирү срогы тәмамланганга кадәр дата билгеләнергә мөмкин, шуннан соң Министрлыкка «Электрон бюджет» системасында сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелгән заявкаларга керү мөмкинлеге бирелә.

6.2. Министрлык, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларны ачу көненнән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, заявкаларны ачу беркетмәсенә имза куя, анда сайлап алуда катнашу өчен кергән заявкалар турында түбәндәге мәгълүмат бирелә:

заявканы теркәү номеры;

заявка керү датасы һәм вакыты;

сайлап алуда катнашучының тулы исеме;

юридик затның адресы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан соратып алына торган субсидия күләме.

6.3. Заявкаларны ачу беркетмәсе бердәм порталда автомат рәвештә булдырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесенең (ул вәкаләт биргән затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана, шулай ук бердәм порталда имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча урнаштырыла.

6.4. Әгәр заявка сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килсә һәм әгәр заявканы кире кагу өчен нигезләр булмаса, ул дөрес дип танылa.

Заявканың сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килүе хакында карар Министрлык тарафыннан сайлап алуда катнашучы заявка белән бергә биргән мәгълүматны һәм документларны тикшерү нәтиҗәләре алынган көндә кабул ителә.

6.5. Заявканы карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

сайлап алуда катнашучының сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның һәм (яки) заявканың сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

заявка составында тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе.

6.6. Кергән заявкаларны рангларга бүлү аларның керү чиратыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

6.7. Сайлап алуда җиңүче итеп әлеге Тәртипнең 1.10 һәм 2.1 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган һәм заявкасы чират буенча беренче итеп тапшырылган сайлап алуда катнашучы танылa.

6.8. Сайлап алуны тәмамлау һәм сайлап алуда җиңүчене билгеләү максатларында сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе булдырыла. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе бердәм порталда сайлап алуда җиңүчене билгеләү нәтиҗәләре буенча автомат рәвештә формалаштырыла һәм «Электрон бюджет» системасында Министрлык җитәкчесе (ул вәкаләт биргән зат) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсе, аңа имза куелган көннән соң килә торган бер эш көненнән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм, сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла һәм түбәндәге мәгълүматларны үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

6.9. Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсендә әлеге Тәртипнең 6.8 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыга бирү өчен каралган субсидия күләмен күрсәткәндә, әгәр ул сорый торган субсидия күләме әлеге Тәртиптә билгеләнгән субсидия күләмен исәпләү тәртибенә туры килмәгән булса, Министрлык әлеге сайлап алуда катнашучыга каралган субсидия күләменә, әмма ул заявкада күрсәткән күләмнән артмаган күләмдә төзәтмә кертә.

Сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенә үзгәрешләр кертү, сайлап алуга йомгаклар ясау беркетмәсенең беренче версиясенә имза куелган көннән алып

10 календарь көннән дә соңга калмыйча, мондый үзгәрешләр кертү сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге Тәртипнең 6.8 пунктында билгеләнгән аны формалаштыру тәртибендәге кебек тәртиптә әлеге беркетмәнең яңа версиясен формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

6.10. Сайлап алу түбәндәге очракларда булмаган дип таныла:

заявкалар бирү срогы тәмамланган көнгә бер генә заявка да бирелмәгән;

заявкаларны карау нәтиҗәләре буенча барлык заявкалар кабул ителмәгән.

## VII. Килешүләр төзү һәм субсидия күчерү тәртибе

7.1. Сайлап алу нәтиҗәләре буенча Министрлык белән сайлап алуда җиңүче арасында, сайлап алуда җиңүче билгеләнгәннән соң 12нче эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә килешү төзелә.

Килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ рәвешендә төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән кул куела.

Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, Килешүнең яңа таләпләр буенча килешенмәгәндә Килешүнең яки килешүне өзү хакында яңа шартларны килештерү турында шарт.

Килешү үз эченә субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерүгә субсидия алучының ризалыгы.

Субсидия алучы, шулай ук субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

7.2. Субсидия алучы кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә, хокук варисы булып торган юридик затны күрсәтеп, йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә.

Субсидия алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай

ук субсидия алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, субсидия алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

7.3. Министрлык, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән таләпләргә сайлап алуда җиңүче туры килмәү факты ачыкланган яки сайлап алуда җиңүче тарафыннан дөрес булмаган мәгълүмат бирелгән очракта, сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарта.

7.4. Министрлык әлеге Тәртипнең 7.3 пунктында каралган нигезләр буенча сайлап алуда җиңүче белән килешү төзүдән баш тарткан, сайлап алуда җиңүче килешү төзүдән баш тарткан очракта, сайлап алуда җиңүче тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән срок эчендә килешүгә имза куелмаган очракта, Министрлык заявкалар рейтингында заявкасы кими бара торган тәртиптә килә торган сайлап алуда катнашучы белән килешү төзи.

7.5. Сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокуклы затның килешүгә кул куюы тәэмин ителмәгән очракта, субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

7.6. Министрлык, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә билгеләнгән килешүләр төзү тәмамлану срогы көненнән алып бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

7.7. Субсидия килешү төзелгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына күчерелә.

## VIII. Хисаплылык бирү, субсидия бирү шартларының һәм тәртибенең үтәлешен контрольдә тотуны (мониторинглауны) гамәлгә ашыру тәртибе һәм аларны бозган өчен җаваплылык

8.1. Субсидия алучы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, «Электрон бюджет» системасы аша Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан килешүләр өчен билгеләнгән бертип формада каралган форма буенча хисаплар тапшыра:

субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап;

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны

тормышка ашыру турында хисап.

8.2. Министрлык әлеге Тәртипнең 8.1 пунктында каралган, субсидия алучы тарафыннан тапшырылган хисапларны «Электрон бюджет» системасында аларны алган датадан 20 эш көне эчендә тикшерә.

8.3. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүгә һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларга (контроль нокта) мониторинг Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслаган субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә мониторинг үткәрү тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

8.4. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

8.5. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча бозулар ачыкланган очракта, субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракта, субсидия акчасы Татарстан Республикасы бюджетына тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

Министерлык әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацлары нигезендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару өчен нигез булган вакыйгалар ачыкланган көннән алып 30 календарь көннән артмаган срок эчендә субсидия алучыга әлеге таләп алынган көннән алып 10 календарь көн эчендә субсидия акчасын кире кайтару турында таләп җибәрү юлы белән субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә.

Субсидия алучы субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан яки читләшкән очракта, Министрлык аларны мәҗбүри түләтү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар күрә.

8.6. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия алучы Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча әлеге чараларга ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алынган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә. Килешүгә өстәмә килешү «Электрон бюджет» системасында электрон документ формасында төзелә һәм һәр як исеменнән эш итәргә хокуклы затларның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.